РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 29 » 02 2024 г. № 209

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 14 ноябрендәге «2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында»гы 1797 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ Федераль закон, 2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 14 сентябрендәге «Дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларны бушлай кайнар туклану белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында»гы 991 санлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 1 сентябрендәге «2023 елга айлык акчалата һәм башка түләүләр турында»гы 934 санлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнар гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында»гы 1122 санлы карары, РФ Баш дәүләт санитар табибының 2020 елның 28 сентябрендәге «Балалар һәм яшьләрне тәрбияләү һәм укыту, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 2.4.3648-20 санитар кагыйдәләрен раслау турында»гы 28 санлы карары, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан

Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 14 ноябрендәге 1797 санлы карарына» Татарстан Республикасы Ютазы районы Прокуратурасының 2024 елның 31 гыйнварындагы 02-08-01/1 санлы протесты нигезендә, балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында балансланган кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының норматив хокукый актларын Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 14 ноябрендәге «2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында»гы 1797 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ Федераль закон, 2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 14 сентябрендәге «Дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларны бушлай кайнар туклану белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында»гы 991 санлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 1 сентябрендәге «2023 елга айлык акчалата һәм башка түләүләр турында»гы 934 санлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнар гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында»гы 1122 санлы карары, РФ Баш дәүләт санитар табибының 2020 елның 28 сентябрендәге «Балалар һәм яшьләрне тәрбияләү һәм укыту, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 2.4.3648-20 санитар кагыйдәләрен раслау турында»гы 28 санлы карары, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 14 ноябрендәге 1797 санлы карарына» Татарстан Республикасы Ютазы районы Прокуратурасының 2024 елның 31 гыйнварындагы 02-08-01/1 санлы протесты нигезендә, балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль

районының гомуми белем бирү оешмаларында балансланган кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:»;

1.2. Карарның 1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча бер укучыга айлык акчалата түләү (иртәнге аш, төшке аш) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетыннан ата-аналарны (законлы вәкилләрне) ата-ана взносларын түләүдән азат итү юлы белән, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре тарафыннан расланган, өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ булган, 18 яшькә яки 23 яшькә кадәр, әгәр дә ул көндезге уку формасы буенча белем бирү эшчәнлеген алып баручы оешмада белем алса, өч һәм аннан да күбрәк баласы булган, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән күп балалы гаиләләрдән, инвалид-балаларга, укучылар исемлеге нигезендә:

- Урыссу ш.т.бистәсендә 64 сум 40 тиен күләмендә;
- авыл җирлегендә 61 сум 20 тиен күләмендә.».

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 14 ноябрендәге «2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында»гы 1797 санлы карары белән расланган «2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы өстәмә социаль ярдәм итүгә мохтаҗларга тукландыруны оештыру тәртибе турындагы Нигезләмә»гә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1. Нигезләмәнең 1 пунктының 1.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Россия Федерациясе Президентының 2023 елның 23 гыйнварындагы «Күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында»гы 63 санлы Указы нигезендә - 18 яшькә яки 23 яшькә кадәрге, әгәр дә ул көндезге уку формасы буенча белем бирү эшчәнлеген алып баручы оешмада белем алса, өч һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдәге балалар ике тапкыр бушлай туклану (иртәнге һәм төшке аш) белән тәэмин ителә.

Нигез буларак тора:

- укучыны оешмага кабул итү турында учреждение боерыгы;
- бушлай туклану турында гариза;
- гаиләне тикшерү акты;
- статусны раслаучы документ - күп балалы гаилә таныклыгы.»;

2.2. Нигезләмәнең 1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«1.4. Укучыларга адреслы социаль ярдәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә туклану (төшке аш) өчен ата-ана взносларын түләүдән өлешчә азат итү юлы белән гомуми белем бирү учреждениеләренең расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә башкарыла һәм түбәндәгеләргә бирелә:

- ата-аналары 1нче һәм 2нче инвалидлык төркеменә ия булган балаларга;
- опекадагы балаларга;
- атасыз яки анасыз тәрбияләнүче балаларга.».

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 8 февралендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 14 ноябрендәге «2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында»гы 1797 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы 107 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Р.М. Якупов
т. 2-42-05